## 5 нче сыйныф

## Татар әдәбиятыннан тест

## Татар халык әкиятләре

**1. Нәрсә ул әкият?**

а) халык иҗатының эпик жанрларыннан берсе, могҗизалы һәм маҗаралы вакыйгаларга, көнкүрешкә бәйләнешле хәлләргә корылган социаль эчтәлекле фантастик әсәр;

ә) кыска, образлы, шигъри формадагы, гыйбрәтле, тормыш итү тәҗрибәсенә нигезләнгән халык авыз иҗаты әсәре;

б) бала тирбәткәндә җырлана торган җыр.

**2. Әкиятләр ничә төркемгә бүленә?**

а) ике;

ә) биш;

б) өч.

**3. «Төлке белән Торна», «Аю белән Төлке», «Кәҗә белән Сарык» әкиятләре нинди төргә карый?**

а) тылсымлы әкият;

ә) көнкүреш әкияте;

б) хайваннар турындагы әкият.

**4. Татар халык әкиятләренең төзелеше (композициясе) нинди?**

а) башлам, эпик өлеш (төенләнеш, вакыйгалар үсеше, кульминация ноктасы, чишелеш), бетем;

ә) эпик өлеш (төенләнеш, вакыйгалар үсеше, кульминация ноктасы, чишелеш), башлам, бетем;

б) бетем, башлам, эпик өлеш (төенләнеш, вакыйгалар үсеше, кульминация ноктасы, чишелеш).

**5.Сүзтезмәләр арасыннан метафораны билгеләгез.**

а) кабыргаларын санау;

ә) ай үсәсен көн үсә;

б) хәйләкәр төлке.

**6. Метафора нәрсә ул?**

а) бер предметны яки күренешне ачыклап бирү өчен, аңа охшаш икенче предмет билгеләрен күчерелмә мәгънәдә куллану;

ә) әйбер яки хәл-күренешнең аерым сыйфатын түгел, ә үзен гадәттән тыш арттырып, зурайтып күрсәтә торган сурәтләү алымы;

б) предметның исеменә ялганып, аның нинди дә булса үзенчәлеген яки сыйфатын билгели, аның сәнгатьлелеген, поэтик көчен арттыра торган сүз.

**7. Нәрсә ул гипербола?**

а) бер предметны яки күренешне ачыклап бирү өчен, аңа охшаш икенче бер предмет билгеләрен күчерелмә мәгънәдә куллану;

ә) әйбер яки хәл-күренешнең аерым сыйфатын түгел, ә үзен гадәттән тыш арттырып, зурайтып күрсәтә торган сурәтләү алымы;

б) предметның исеменә ялганып, аның нинди дә булса үзенчәлеген яки сыйфатын билгели, аның сәнгатьлелеген, поэтик көчен арттыра торган сүз.

## Ачкыч

1. **А**
2. **Б**
3. **Б**
4. **А**
5. **А**
6. **А**
7. **Ә**

# Бәяләү

## 6-7 балл – “5”ле

## 5 балл – “4”ле

## 3-4 балл – “3”ле